**2024лның 30 октябре**

**СОВЕТ ДЕРЖАВИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422620,Татарстан, с. Державино,
ул. Заббарова, д.39
тел: 3-45-20

**57-2 номер**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДЕРЖАВИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422620 Державино авылы,
Заббаров урамы, 39 нчы йорт,
тел: 3-45-20

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлегенең Державино торак пунктында гражданнар җыены карары

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лаеш муниципаль районының Державино авыл җирлегендәге Державино торак пункты гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлегенең Державино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2025 елда үзара салым салу акчаларын 1000 сум күләмендә түбәндәге эшләрне эшләргә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- ремонт, коймалар кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү буенча эшләр өчен түләүгә юллау.

3. Әлеге карарны Державино авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында игълан итәргә, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: ________________ И.И. Камалиева
(имза) (имза расшифровкасы)

Башлык-Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Державино
авыл җирлеге Советы рәисе: ________________ И.И. Камалиева
(имза)(имза расшифровкасы)